ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОРУССКО-МАМАТКОЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Красавина, д.40, с. Набережные Моркваши, 422594

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ЯҢА РУС МӘМӘТХУҖАСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Үзәк ур., 28 нче йорт, М. Вахитов исем авылы, 422575

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

22.10.2019 с. Старое Русское Маматкозино 56

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлегенең Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2019 елның 5 ноябренә Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. «2020 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган һәр авыл җирлеге кешесеннән 500 сум үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен алдагы эшләрне башкаруга җибәрү белән килешәсезме:

- Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылында юл вак таш җәю;
- Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылындагы зиратны коймалау өчен материал сатып алу, урнаштыру

« ӘЙЕ» «ЮК»

3. Халык җыенын Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылы, Дорожная урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан Мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

4. Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

**Югары Ослан муниципаль районы**
**Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге**
**Башлыгы** **В.В.Никитушкин**